| ГОРОДСКОЙ СОВЕТ МУНИЦИПАЛЬНОГО ОБРАЗОВАНИЯ ГОРОД НАБЕРЕЖНЫЕ ЧЕЛНЫ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН | ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ЯР ЧАЛЛЫ ШӘҺӘРЕ МУНИЦИПАЛЬ БЕРӘМЛЕГЕ ШӘҺӘР СОВЕТЫ |
|---|---|
| **РЕШЕНИЕ** | **КАРАР** |
| 22 октябрь, 2015 ел | № 2/19 |

Шәһәр Советының Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлегендә муниципаль хезмәт мәсьәләләре буенча аерым карарларына үзгәрешләр кертү турында

Татарстан Республикасының 2013 елның 25 июнендәге «Татарстан Республикасының муниципаль хезмәт турында кодексы» 50-ЗРТ санлы Законы, Яр Чаллы шәһәре Уставының 28, 48, 49 маддәләре нигезендә

Шәһәр Советы

КАРАР бирде:

1. Шәһәр Советының 2008 елның 18 апрелендәге «Яр Чаллы шәһәрендә муниципаль хезмәт турында» 31/13 санлы Карарына (Шәһәр Советының 2009 елның 9 апрелендәге 40/23, 2012 елның 20 сентябрендәге 21/11, 2013 елның 29 августындагы 26/15 санлы Карарлары редакциясендә) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1) 1 кушымтада 4 бүлекнең 7 пункт 1 пунктчасын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«1) һөнәри белем дәрәҗәсенә: вазифаларның югары, баш һәм әйдәүче төркемнәре өчен эшчәнлек юнәлешенә туры килә торган югары белем булу; вазифаларның өлкән һәм кече төркемнәре өчен эшчәнлек юнәлешенә туры килә торган югары белем яки урта һөнәри белем булу;»;

2) 2 кушымтада:

а) 3 бүлекнең 18 пункты 3 пунктчасын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«3) өстәмә һөнәри белемне уңышлы алган шартта, биләгән муниципаль хезмәт вазифасына туры килә;»;

б) 3 бүлекнең 21 пункты 2 пунктчасын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«2) өстәмә һөнәри белем алу өчен җибәрелә;»;

в) 3 бүлекнең 22 пунктында «һөнәр буенча яңадан уку, квалификацияне күтәрү» сүзләрен «өстәмә һөнәри белем алу» сүзләренә

алыштырырга;

3) муниципаль хезмәткәрләргә аттестация уздыру турында Нигезнамәгә кушымтаның 10 пунктында «һөнәр буенча яңадан укыганда яки квалификацияне күтәргәндә» сүзләрен «өстәмә һөнәри белемне уңышлы алганда» сүзләренә алыштырырга.

2. Шәһәр Советының 2010 елның 15 июлендәге 52/6 санлы Карары (Шәһәр Советының 2012 елның 20 сентябрендәге 21/11, 2013 елның 29 августындагы 26/15 санлы Карарлары редакциясендә) белән расланган Яр Чаллы шәһәрендә муниципаль хезмәткәрләр тарафыннан хезмәт вазифаларын үтәү өчен кирәкле булган муниципаль хезмәтнең вазифаларын биләүгә квалификация таләпләренә 2 бүлекнең 4 пунктын түбәндәге редакциядә бәян итеп үзгәрешләр кертергә:

«4. Һөнәри белем дәрәҗәсенә түбәндәге квалификация таләпләре билгеләнә:

1) муниципаль хезмәт вазифаларының югары, баш һәм әйдәүче төркемнәре өчен – эшчәнлек юнәлешенә туры килә торган югары һөнәри белем булу;

2) муниципаль хезмәт вазифаларының өлкән һәм кече төркемнәре өчен – югары белем яки урта һөнәри белем булу.».

3. Әлеге Карар үтәлешен тикшереп торуны Шәһәр Советының регламент, хокук тәртибе һәм халык иминлеген тәэмин итү мәсьәләләре буенча даими комиссиясенә йөкләргә.

Шәһәр Хакиме Н.Г. Мәһдиев